# Лемаев мәйданы.



Туган якны Гомәр Бәширов яшел бишек белән тиңли. Чыннан да Түбән Кама яшеллеккә күмелгән. Шәһәребез бөтен табигать матурлыгын үз эченә сыйдырган. Шәһәр үзәгендә искиткеч матур урын бар. Бу - Лемаев мәйданы. Николай Васильевич Лемаев – “Түбән Кама нефтехим“ берләшмәсенең беренче генераль директоры. Анда мәйданда һәйкәл куелган. Һәйкәл янында һәрвакыт чәчәкләр тора. Лемаев мәйданында “Җәлил” ял үзәге, кафелар бар. Кашкарый, лалә, петуния, кыңгырау чәчәкләре үскән түтәлләр янында рәхәтләнеп ял итәргә мөмкин. Матур фонтаннар мәйданга ямь өсти. Бу мәйданны олылар да, балалар да бик ярата.